КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.04.2020 № 57-П

г. Казань

“Татар галиме һәм мәгърифәтчесе Шәмсетдин Күлтәси кабере (1857 - 1932)”, 1857 – 1932 еллар, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен раслау турында

2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» Федераль закон нигезендә, 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы законы белән, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын һәм аларның территорияләрен махсус җайга салу шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары буларак саклап калу һәм дәүләт саклавы максатларында, **боерам:**


1. Татарстан Республикасы, Арчу муниципаль районы, Үрнәк авыл җирлеге, Күлтәс авылы зираты адресы буенча урнашкан “Татар галиме һәм мәгърифәтчесе Шәмсетдин Күлтәси кабере (1857 - 1932)”, 1857 – 1932 еллар, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен әлеге боерыкка 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы, Арчу муниципаль районы, Үрнәк авыл җирлеге, Күлтәс авылы зираты адресы буенча урнашкан “Татар галиме һәм мәгърифәтчесе Шәмсетдин Күлтәси кабере (1857 - 1932)”, 1857 – 1932 еллар, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясеннән файдалану режимын әлеге боерыкка 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Боерыкның үтәлешен тикшерүне үз өстемдә калдырам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы мәдәни
мирас объектларын саклау
комитетының
«07» 04.2020 № 57-П
боерыгына 1 кушымта

“Татар галиме һәм мәгърифәтчесе Шәмсетдин Күлтәси кабере (1857 - 1932)”, 1857 – 1932 еллар, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе **ЧИКЛӘРЕ**

1. “Татар галиме һәм мәгърифәтчесе Шәмсетдин Күлтәси кабере (1857 - 1932)”, 1857 – 1932 еллар, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картасы (схемасы)**




Мәдәни мирас объектының топографик планы

“Татар галиме һәм мәгърифәтчесе Шәмсетдин Күлтәси кабере (1857 - 1932)”, 1857 – 1932 еллар, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картографик тасвирламасы**

Төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чиге түбәндәгечә уза:

көнбатыш өлеше: металл киртә буйлап (1-2 характерлы нокталары);
төньяк өлеше: металл киртә буйлап (2-3 характерлы нокталары);
көнчыгыш өлеше: металл киртә буйлап (3-4 характерлы нокталары);
көньяк өлеше: металл киртә буйлап (4-1 характерлы нокталары).

“Татар галиме һәм мәгърифәтчесе Шәмсетдин Күлтәси кабере (1857 - 1932)”, 1857 – 1932 еллар, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **характерлы нокталары таблицасы**

| Нокта № | Координаталарның җирле системасында нокта координаталары (МСК-16) | | 1984 елгы бөтендөнья геодезия системасында нокта координаталары (WGS-84) | |
|---|---|---|---|---|
| | X | Y | **төньяк киңлек B** | **көнчыгыш озынлык L** |
| 1 | 527168,35 | 1359521,09 | 56°14'49.91"N | 49°59'30.47"E |
| 2 | 527170,17 | 1359518,41 | 56°14'49.97"N | 49°59'30.31"E |
| 3 | 527171,81 | 1359519,52 | 56°14'50.02"N | 49°59'30.38"E |
| 4 | 527170,01 | 1359522,17 | 56°14'49.96"N | 49°59'30.53"E |

Татарстан Республикасы
мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының
«07» 04.2020 № 57-П
боерыгына 1 кушымта

“Татар галиме һәм мәгърифәтчесе Шәмсетдин Күлтәси кабере (1857 - 1932)”, 1857 – 1932 еллар, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясеннән **файдалану режимы**

“Татар галиме һәм мәгърифәтчесе Шәмсетдин Күлтәси кабере (1857 - 1932)”, 1857 – 1932 еллар, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

а) мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү таләпләренә каршы килмәгән һәм мәдәни мирас объектының хәзерге шартларда эшләвен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган хуҗалык эшчәнлеген алып бару;

б) мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен - мәдәни мирас объектының физик сакланышын тәэмин итүгә, ремонт-реставрация эшләрен (шул исәптән мәдәни мирас объектын консервацияләүгә, һәйкәлне реставрацияләүгә, мәдәни мирас объектын заманча файдалануга яраклаштыруга) юнәлтелгән эшләрне «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәгән килеш уздыру;

в) мәдәни мирас объектын күрсәтү объекты буларак экскурсия һәм туристлык маршрутларына кертү юлы белән популярлаштыру, шул исәптән аны музейлаштыру;

г) гражданнарның мәдәни мирас объектыннан файдалана алуын тәэмин итү;

д) территорияне төзекләндерү эшләрен башкару, традицион материаллар (кирпеч, таш, гранит һәм башка табигый материаллар, шулай ук табигый материалларга охшаш материаллар) кулланып.

2. Җирле (муниципаль) әһәмияттәге күрсәтелгән мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрендә түбәндәгеләр **тыела:**

а) җимерелү, тулаем һәйкәлне яисә аның аерым өлешләрен җимерү, өстәү, һәртөрле даими һәм вакытлы биналар һәм корылмалар төзү;

б) капиталь төзелеш объектларын төзү һәм һәйкәл территориясендә булган

капиталь төзелеш объектларының күләм-пространство характеристикаларын арттыру; мәдәни мирас объектын яисә аның аерым элементларын саклап калу, мәдәни мирас объектының тарихи-шәһәр төзелеше яисә табигый мохитен саклау эшләреннән тыш, җир, төзелеш, мелиоратив һәм башка эшләр башкару;

в) мәдәни мирас объектын җимерүгә алып бара торган һәм аңа зыян килү яисә юкка чыгару куркынычы тудыра торган хуҗалык эшчәнлеге;

г) чүп-чар, көнкүреш калдыклары чүплеге.